**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: : 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 нчы елның 4 нче сентябре 307№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының
2009 нчы елның 4 нче мартындагы 93 номерлы
"2019-2023 елларга Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районында кече һәм урта
эшмәкәрлек субъектларын үстерү муниципаль
программасын раслау турында" карарына
үзгәрешләр кертү турында

Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты гражданнарның иминлеген арттыру һәм икътисадый актив урта класс формалаштыру, Әлки муниципаль районының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 нчы елның 4 нче мартындагы 93 номерлы "2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү муниципаль программасын раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.Алтынчы абзацның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны башкаручылар | Әлки муниципаль районы башкарма комитеты; кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары; районның кредит учреждениеләре(килешү буенча), Россия Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 18 нче районара инспекциясе(килешү буенча); "Әлки районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ(килешү буенча); «Әлки муниципаль районында мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ (килешү буенча), ТР Нурлат шәһәрендә РПФ ДУ (районара) клиентлык хезмәте (килешү буенча), «Татарстан Республикасының БТИ " АҖ Нурлат филиалының Әлки бүлекчәсе (килешү буенча), Әлки муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе(килешү буенча); "Татмедиа" АҖ филиалы " Әлки хәбәрләре» газетасы редакциясе (килешү буенча), Район башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча |

| | ярдәмчесе (килешү буенча) |
|---|---|

3.Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 нче елның 28 нче декабрендәге 16 номерлы “2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү муниципаль программасын раслау турында" карарын 2019 нчы елның 1 нче мартыннан үз көчен югалткан дип санарга.

4.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Т. Ф. Билаловка йөкләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе Йосыпов И.В.